**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 октябрендәге 4320 номерлы карары**

## 2024 елда Казан шәһәрендә БРИКС илләре саммитын әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен, тукталышын һәм туктап торуын вакытлыча чикләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 353 номерлы «Рәсми спорт ярышлары уздырганда куркынычсызлыкны тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. БРИКС илләре саммитын әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны парковкага куюны вакытлыча чикләүне әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә билгеләргә;

1.2. БРИКС илләре саммитын әзерләү һәм уздыру чорында Вишневский урамы буйлап, Подлужная, Николай Ершов, Шмидт, Лесгафт, Калинин, Тихомирнов, Петербург урамнары белән кисешкән урыннарда, Нурсолтан Назарбаев урамы буйлап, Островский, Спартак, Марсель Сәлимҗанов, Һади Такташ урамнары белән кисешкән урыннарда, «Миллениум» күпереннән Габдулла Тукай урамына таба хәрәкәт итү юнәлешендә 4.1.1 «Туры хәрәкәт итү» юл билгеләрен урнаштыру өлешендә юл хәрәкәтен оештыруга вакытлыча үзгәрешләр кертергә;

1.3. 2024 елның 19 октябреннән 24 октябренә кадәрге чорда Казан шәһәренең Мехчылар, Девятаев, Мәҗит Гафури, Ирек, Кызыл Татарстан,

Татарстан урамнарында тәүлекнең көндезге вакытында, 06.00 сәгатьтән 21.00 сәгатькә кадәр, рөхсәт ителгән авырлыгы 5 тоннадан артык булган транспорт чаралары хәрәкәтен тыюны кертергә;

1.4. Мехчылар урамы буенча хәрәкәт иткәндә Кызыл Татарстан урамына таба һәм Габдулла Тукай урамы буенча хәрәкәт иткәндә Татарстан урамына таба сул борылышларны вакытлыча рөхсәт итәргә;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.5.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру схемаларын эшләргә, аларны урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.5.2. транспорт предприятиеләренә юлларны ябу һәм җәмәгать транспорты маршрутлары үзгәрү турында хәбәр итәргә;

1.5.3. троллейбус челтәрен электр белән туендыру юлларын өзүне тәэмин итәргә;

1.5.4. транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны парковкага куюны вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендәге «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.5.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты (И.И.Сәлахетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты (В.А.Лысачкин), Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә кушымта нигезендә хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында таранга каршы техниканы урнаштыруны тәэмин итәргә;

1.6. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов):

1.6.1. чараны уздыру чорында ремонт-төзелеш эшләрен башкару графигына төзәтмәләр кертергә;

1.6.2. чараларны әзерләгәндә транспорт керү юлларын һәм парковка урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы эшләр башкарырга, чаралар тәмамланганнан соң, чаралар уздырыла торган урыннарга якын урнашкан урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә;

1.7. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны контрольдә тотуны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны парковкага куюны вакытлыча чикләү кертелү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 15 октябрендәге
4320 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**БРИКС илләре саммитын уздыру чорында**
**Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен**
**һәм аларны парковкага куюны чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2024 елның 22 октябрендә 00.00 сәгатьтән 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр | - Большая Красная урамында, Жуковский урамыннан Япеев урамына кадәрге участокта;<br>- Карл Маркс урамында, Жуковский урамыннан Япеев урамына кадәрге участокта;<br>- Театр урамында, Дзержинский урамыннан Касаткин урамына кадәрге участокта;<br>- Пушкин урамында, Дзержинский урамыннан Бассейн урамына кадәрге участокта;<br>- Карл Фукс урамында, Бехтерев урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;<br>- Лобачевский урамында, Большая Красная урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;<br>- Кремль урамында, Беренче Май мәйданыннан Профессор Нужин урамына кадәр |
| 2 | 2024 елның 16 октябрендә 00.00 сәгатьтән 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр | - Оренбург Тракты урамындагы җирле юл буйлап, Универсиада авылы янында, Җиңү проспектыннан Академик Парин урамына кадәр;<br>- Оренбург Тракты урамындагы 95 номерлы йорт янында 16:50:171128:173 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан парковкага керү;<br>- Петербург урамы буйлап җирле юл буенча |
| 3 | 2024 елның 22 октябрендә 00.00 сәгатьтән 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | - Пушкин урамында, Марсель Сәлимҗанов урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;<br>- Татарстан урамында, Габдулла Тукай урамыннан Марсель Сәлимҗанов урамына кадәрге участокта;<br>- Вишневский урамында, Подлужная урамыннан Тихомирнов урамына кадәрге участокта;<br>- Нурсолтан Назарбаев урамында, Тихомирнов урамыннан Һади Такташ урамына кадәрге участокта;<br>- Карл Маркс урамында, Чехов урамыннан Жуковский урамына кадәрге участокта;<br>- Большая Красная урамында, Толстой урамыннан Жуковский урамына кадәрге участокта;<br>- Толстой урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта; |

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| | | - Лобачевский урамында, Дзержинский урамыннан Кремль урамына кадәр;<br>- Подлужная урамында, Толстой урамыннан Жуковский урамына кадәрге участокта;<br>- Жуковский урамында, Подлужная урамыннан Адамюк урамына кадәрге участокта;<br>- Адамюк урамында, Жуковский урамыннан Малая Красная урамына кадәрге участокта;<br>- Малая Красная урамында, Адамюк урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта;<br>- Бассейн урамында, Малая Красная урамыннан Пушкин урамына кадәрге участокта;<br>- Касаткин урамында, Театр урамыннан Федосеев урамына кадәрге участокта;<br>- Пушкин урамында, Бассейн урамыннан Пушкин урамындагы 78 номерлы йортка кадәрге участокта;<br>- Пушкин урамыннан Касаткин урамына кадәрге юл (1 номерлы йорт, Ирек мәйданы);<br>- Кызыл Татарстан урамында, Мәҗит Гафури урамыннан Ирек урамына кадәрге участокта;<br>- «Вахитов» тимер юл станциясе буйлап автомобиль юлы буенча, Ирек урамыннан Кызыл Татарстан урамына кадәр |
| 4 | 2024 елның 18 октябрендә 00.00 сәгатьтән 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | - Рауис Гәрәев урамында урнашкан 117 номерлы йорт янәшәсендәге җирле юлда;<br>- Җиңү проспектындагы 34 номерлы йорт буйлап урнашкан юлда транспорт чаралары парковкасына керү;<br>- Җиңү проспекты буйлап җирле юлда, Хөсәен Мәүлүтев урамыннан Оренбург Тракты урамына кадәрге участокта |

______________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 15 октябрендәге
4320 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**БРИКС илләре саммитын уздырганда**
**Казан шәһәренең автомобиль юлларында**
**транспорт чараларын парковкага куюны вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2024 елның 19 октябрендә 00.00 сәгатьтән 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр | - Пушкин урамында, Марсель Сәлимҗанов урамыннан Бассейн урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Универсиада проспектында, Тихомирнов урамыннан Оренбург Тракты урамына кадәр участокта ике юнәлештә;<br>- Оренбург Тракты урамында, Универсиада проспектыннан Казан шәһәре чигенә кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Оренбург Тракты урамында урнашкан 172 номерлы йорт янәшәсендәге автомобиль юлы буйлап;<br>- Татарстан урамында, Габдулла Тукай урамыннан Марсель Сәлимҗанов урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Вишневский урамында, Подлужная урамыннан Тихомирнов урамына кадәр участокта ике юнәлештә;<br>- Нурсолтан Назарбаев урамында, Тихомирнов урамыннан Һади Такташ урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Петербург урамында, Туфан Миңнуллин урамыннан Ульянов-Ленин урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Университет урамында, Уң як Болак урамыннан Кремль урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Профсоюз урамында, Пушкин урамыннан Ташаяк урамына кадәр ике яктан;<br>- Ташаяк урамында, Меңьеллык мәйданыннан Сәетгалиев урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Сәетгалиев урамында, Ташаяк урамыннан Рөстәм Яхин урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Борһан Шәһиди урамында, Рөстәм Яхин урамыннан Чернышевский урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Кызыл Татарстан урамында, Мәҗит Гафури урамыннан Ирек урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Чернышевский урамында, Дзержинский урамыннан Борһан Шәһиди урамына кадәрге участокта ике юнәлештә; |

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| | | - Гаяз Исхакый урамында, Чернышевский урамыннан Таҗи Гыйззәт урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Щербаков тыкрыгында, Пушкин урамыннан Тихомирнов урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Артем Айдинов урамында, Тихомирнов урамыннан Марсель Сәлимҗанов урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Островский урамында, Артем Айдинов урамыннан Муса Җәлил урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Туфан Миңнуллин урамында, Тихомирнов урамыннан Островский урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Николай Ершов урамында урнашкан 1 номерлы йорт янәшәсендәге юл буйлап ике юнәлештә;<br>- Фатыйх Әмирхан урамында, «Миллениум» күпере астындагы борылыш элмәге, Фатыйх Әмирхан урамындагы 1 номерлы йорттан 1г номерлы йортка кадәр ике яктан;<br>- Николай Ершов урамында, Вишневский урамыннан Чехов урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Карл Маркс урамында, Чехов урамыннан Театр урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Большая Красная урамында, Толстой урамыннан Жуковский урамына кадәрге участокта ике яктан;<br>- Кремль урамында, Кремльдән Университет урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Лобачевский урамында, Профсоюз урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Театр урамында, Дзержинский урамыннан Касаткин урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Бассейн урамында, Пушкин урамыннан Малая Красная урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Малая Красная урамында, Адамюк урамыннан Большая Красная урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Карл Фукс урамында, Бехтерев урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта ике яктан;<br>- Толстой урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәр ике яктан;<br>- Жуковский урамында, Большая Красная урамыннан Карл Маркс урамына кадәр ике яктан;<br>- Мәскәү урамында, Таҗи Гыйззәт урамыннан Ташаяк урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Таҗи Гыйззәт урамында, Мәскәү урамыннан Борһан Шәһиди урамына кадәрге участокта ике юнәлештә;<br>- Уң як Болак урамында, Пушкин урамыннан Ташаяк урамына кадәр ике яктан;<br>- Сул як Болак урамында, Ташаяк урамыннан Татарстан урамына кадәр ике яктан;<br>- Лесгафт урамында, Айвазовский урамыннан Волков урамына кадәр ике юнәлештә; |

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| | | - Волков урамында, Лесгафт урамыннан Айвазовский урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Айвазовский урамында, Волков урамыннан Роща Фрунзе урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Роща Фрунзе урамында, Айвазовский урамыннан Тихомирнов урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Туфан Миңнуллин урамында, Тихомирнов урамыннан Марсель Сәлимҗанов урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Сибгат Хәким урамында, Абдулла Бичурин урамыннан Фатыйх Әмирхан урамына кадәр ике юнәлештә;<br>- Фатыйх Әмирхан урамында, Сибгат Хәким урамыннан «Миллениум» күперенә кадәр ике юнәлештә;<br>- «Миллениум» күпере буйлап ике юнәлештә;<br>- Декабристлар урамында, Горсоветская урамыннан Кремль дамбасына кадәр ике юнәлештә;<br>- Кремль дамбасы буйлап, Декабристлар урамыннан Меңьеллык мәйданына кадәр ике юнәлештә;<br>- Меңьеллык мәйданы буенча ике юнәлештә;<br>- Татарстан урамында, Мәскәү урамыннан Габдулла Тукай урамына кадәрге участокта |
| 2 | 2024 елның 22 октябрендә 00.00 сәгатьтән 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (транспорт корылмалары астындагы мәйданчыкларда) | - Универсиада проспекты – Вишневский урамы;<br>- «Миллениум» күпере астында «Урам» паркы янында;<br>- Фатыйх Әмирхан урамы – Чистай урамы;<br>- Фатыйх Әмирхан урамы – Хөсәен Ямашев проспекты |
| 3 | 2024 елның 16 октябрендә 00.00 сәгатьтән 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (автобуслардан тыш) | - Сыртланова урамында, Гарифьянов урамыннан Хөсәен Мәүлүтев урамына кадәр;<br>- Җиңү проспектындагы җирле юл буйлап, Юлиус Фучик урамыннан Җиңү проспектындагы 50 номерлы йортка кадәр (8.4.11 «Автобуслардан тыш» билгеләрен урнаштыру);<br>- Нәҗип Җиһанов урамында, Альберт Камалиев проспектыннан Сабир Әхтәмов урамына кадәр (8.4.11 «Автобуслардан тыш» билгеләрен урнаштыру);<br>- Петербург урамында, Суконная урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр;<br>- Петербург урамы буйлап җирле юл буенча, Суконная урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр;<br>- Алексей Казем-Бек урамында, Бертуган Батталовлар урамыннан Алексей Казем-Бек урамындагы 3 номерлы йортка кадәрге участокта;<br>- Бертуган Батталовлар урамыннан Белые Росы урамына кадәр автомобиль юлы буйлап;<br>- Рауис Гәрәев урамында урнашкан 117 номерлы йорт янәшәсендә (8.4.11 «Автобуслардан тыш» билгеләрен урнаштыру, 8.5.4 «Гамәлдә булу вакыты» билгесен сүтү яки каплау); |

| №<br>т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
| --- | --- | --- |
| | | - Рауис Гәрәев урамындагы 117а номерлы йорт янәшәсендә (8.4.11 «Автобуслардан тыш», 8.2.4 «Гамәлдә булу зонасы» билгеләрен урнаштыру, 6.4 «Парковка» юл билгеләрен сүтү яки каплау) |